**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 10 июнендәге 1719 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 30 сентябрендәге 4126 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең Идел буе районындагы Авангард һәм Сормово урамнары белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, Россия Федерациясе субъектларының вәкаләтле башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 июлендәге 722 номерлы «2022, 2023, 2024 һәм 2025 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне ызанлау проектларын раслау һәм, җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрмичә, әлеге проектларга үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында»гы карарына таянып, **карар бирәм**:

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә планлаштыру проектының аерым өлешләрен раслау юлы белән Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 30 сентябрендәге 4126 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең Идел буе районындагы Авангард һәм Сормово урамнары белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертергә.

2. Билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән кала (кызыл линияләр күрсәтелгән территорияне планлаштыру сызымына кушымта) (хезмәт урынында файдалана торган материаллар), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 10 июнендәге
1719 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 30 сентябрендәге 4126 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең Идел буе районындагы Авангард һәм Сормово урамнары белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. Кызыл линияләр, планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләре, капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән территорияне планлаштыру проекты сызымын әлеге үзгәрешләрнең 1 номерлы кушымтасы нигезендә редакциялəп бирергә.

2. Кызыл линияләр һәм билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге күрсәтелгән территорияне планлаштыру проекты сызымын әлеге үзгәрешләрнең 2 номерлы кушымтасы нигезендә редакциялəп бирергә.

3. «Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, шулай ук территорияне план буенча үстерү характеристикалары, шул исәптән төзелеш тыгызлыгы һәм параметрлары, территорияне үстерү өчен кирәкле социаль, транспорт хезмәте күрсәтү һәм инженерлык-техник яктан тәэмин итү системаларын үстерү характеристикалары турында нигезләмә» дигән III бүлектә:

3.1. «Инженерлык-техник тәэмин итү системасын үстерү характеристикалары» дигән 4 пунктта:

3.1.1. «Яңгыр канализациясе» дигән 4.3 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«16:50:000000:22494 кадастр номерлы җир кишәрлегендә булган яңгыр канализациясен чистарту корылмалары 16:50:000000:35054 кадастр номерлы җир кишәрлегенә күчерелә»;

3.1.2. «Җылылык белән тәэмин итү» дигән 4.4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«4.4. Җылылык белән тәэмин итү.

Исәп-хисап буенча, мәчетнең җылылыкка ихтыяҗы түбәндәгеләрне тәшкил итә:

- җылытуга җылылык тоту – 0,052 МВт (0,0443 Гкал/сәг);
- җылы идәнгә җылылык чыгымы – 0,036 МВт (0,0305 Гкал/сәг);
- җилләтү өчен җылылык тоту – 0,130 МВт (0,1118 Гкал/сәг);
- кайнар су белән тәэмин итүгә җылылык тоту (максималь) – 0,33 МВт (0,2839 Гкал/сәг);

- кайнар су белән тәэмин итүгә җылылык тоту (уртача) – 0,022 МВт (0,0192 Гкал/сәг).

Җылылык белән тәэмин итүгә гомуми ихтыяҗ 0,57 МВт (0,49 Гкал/сәг) тәшкил итәчәк.

Бирелгән җылылык йөкләнешен каплау өчен Галимҗан Баруди исемендәге проектлана торган мәчет бинасы түбәсендә «ВКТ-2F-500» тышкы куллану казанын урнаштыру күздә тотыла.

Казанның куәте – 500 КВт (0,5 МВт).

Казаннан җылы саклый торган, параметрлары 90-70 ºС булган су аерым җылылык пунктына бирелә»;

3.1.3. «Газ белән тәэмин итү» 4.5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«4.5. Газ белән тәэмин итү.

Мәчетне җылылык һәм кайнар су белән тәэмин итү өчен тышка урнаштырыла торган «EGS ВКТ-F2.500» казанын кую күздә тотыла.

Казанның куәте – 0,5 МВт.

Казанга тотыла торган газ – 52,4 куб.м/сәг.

«Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2024 елның 16 апрелендәге 03/2-4318 номерлы хаты нигезендә Авангард урамында урнашкан 16:50:000000:31854 кадастр номерлы җир кишәрлегендә, 426 мм диаметрлы уртача басымлы газүткәргечкә тоташтырып, планлаштыру объектын табигый газ белән тәэмин итү буенча техник мөмкинлек бар.

Газны «Богородское» газ бүлеп тарату станциясеннән бирү күздә тотыла.

Тышка урнаштырыла торган казанны, аерым торучы шкаф рәвешендәге газ көйләү пунктын урнаштырып, 63 мм диаметрлы урта басымлы җир асты полиэтилен газүткәргече ярдәмендә газ белән тәэмин итү планлаштырыла»;

3.1.4. «Электр белән тәэмин итү» 4.6 пунктчасында:

3.1.4.1. «Китерүче КЛ 10 кВ – 1,1 км төзү» сүзләрен «0,14 км озынлыктагы КЛ 0,4 кВ төзү» сүзләренә алмаштырырга;

3.1.4.2. алтынчы абзацны төшереп калдырырга;

3.1.4.3. түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Электр белән тәэмин итү эшләп килүче ТП-486 трансформатор подстанциясеннән каралган»;

3.2. түбәндәге эчтәлекле «Төзелешне көйләү линиясе» 6 пунктын өстәргә:


«6. Төзелешне көйләү линияләре

Проектта территориядә планлаштырыла торган төзелешнең эшләнгән эскизы нигезендә җир кишәрлеге чикләреннән: көнбатыш яктан – 3 м ераклыкта, төньяк, көньяк һәм көнчыгыш яктан 0 м ераклыкта төзелешне көйләү линияләре (җир кишәрлеге чикләреннән калдырылган ара) билгеләнә».

___________________

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның
30 сентябрендәге 4126 номерлы карары белән расланган
Казан шәһәренең Идел буе районындагы Авангард һәм
Сормово урамнары белән чикләнгән территорияне
планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләргә
1 номерлы кушымта

I. Чертеж проекта планировки территории с указанием красных линий, границ существующих и планируемых элементов планировочной структуры, границ зон планируемого размещения объектов капитального строительства




УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ

- граница территории, в отношении которой осуществляется подготовка проект планировки территории
- граница элемента планировочной структуры
- устанавливаемая красная линия улично-дорожной сети
- действующая красная линия улично-дорожной сети
- действующая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети)
- устанавливаемая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети)
- граница планируемого технического коридора инженерных коммуникаций и сооружений
- линия регулирования застройки
- 1 — порядковый номер зоны размещения
- 5 — вид зоны размещения объектов капитального строительства
- 0.2059 — площадь зоны размещения, га
- 3.7.1 — коды видов разрешенного использования
- н.у. — максимальная площадь жилищного фонда, (тыс.кв.м)
- н.у. — максимальная этажность, этаж
- 5 — зона планируемого размещения объектов культового назначения
- 11 — зона существующего размещения объектов инженерной инфраструктуры
- 20 — зона размещения озелененных территории общего пользования
- 21 — зона размещения объектов улично-дорожной сети
- проектируемая крышная котельная (расположение ориентировочное)
- газораспределительный пункт (расположение ориентировочное)
- существующая БКТП

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның
30 сентябрендәге 4126 номерлы карары белән расланган
Казан шәһәренең Идел буе районындагы Авангард һәм
Сормово урамнары белән чикләнгән территорияне
планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләргә
2 номерлы кушымта

II. Чертеж проекта планировки территории с указанием красных линий




Условные обозначения

- граница территории, в отношении которой осуществляется подготовка проект планировки территории
- устанавливаемая красная линия улично-дорожной сети (красная линия)
- действующая красная линия улично-дорожной сети (красная линия)
- отменяемая красная линия улично-дорожной сети (красная линия)
- устанавливаемая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети) (КЛ ТОП)
- действующая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети) (КЛ ТОП)
- отменяемая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети) (красная линия)
- граница планируемого технического коридора инженерных коммуникаций и сооружений
- 5 условные номера характерных точек устанавливаемых красных линий.
- линия регулирования застройки

**Примечание:**

**Сокращения надписей, принятые на чертеже**

1. КЛ ТОП - красная линия озеленения территории общего пользования